# Ял сәгатьләрендә

*Әдәби байлыгың зурмы?*

***Кешенең акыл-фикеренә,күңел байлыгын барлар өчен шушы тестны тәкъдим итәбез.***

*1.Укуга .белемгә тылмач ул- бу тел,*
*Кешене нурлаган нәрсә тел ул-бел!*

***1096 елда язылган бу юлларның авторы кем?***

*а)Йосыф Баласагунлы;б)Әхмәт Йүгнәки;в)Сөләйман Бакыргани.*

***2.Телнең сүзлек составын лексика дип атыйлар.Сүзнең тарихы,килеп чыгышы лексиканың кайсы тармагында өйрәнелә?***

*а)семасиология;б)этимология;в)ономасиология.*

***3.”Салпы якка салам кыстыру”дигән фразеологизм нәрсә аңлата?***

а) алдау;б) ярдәм итү;в) ялагайлану.

***4.”Авызлары,борыннары җимерелгән сүзләрне яклап” исемле шигырьдә телебезнең бозып әйтелгән рус сүзләре белән чуарлануы турында борчылып язылган.Шигырьнең авторы кем?***

а)Г.Тукай;б)Дәрдмәнд;в)Һ.Такташ.

***5.Аспирант сүзе кайсы телдән кергән?***

а)латин; б) грек; в) француз.

***6.Тел,әдәбият һәм сәнгать институты кем исемендә?***

а) Г.Исхакый;б) Г.Ибраһимов; в) Ф.Әмирхан.

***7.Татар әдәбиятында “Бичара кыз”дигән беренче драма әсәренең авторы***

а) Ф.Халиди;б) Г.Камал; в)Г.Ильяси.

*САБЫЙГА*

**Табышмак әйтәм-тап!**

Ярдәмчеләре бик уңган
Кар, суык, җилле буран,
Көз соңында Җир өстенә
Яба ул ап- ак юрган.
( ышк)

Җиләк кояшта пешә,
Шалкан учакта пешә,
Нәрсә ... суыкта пешә? (лшмэи)

***Тик торып арып беткән,***
***Өч фасыл ул ял иткән.***
***Күзге гөлләр туңып сулгач,***
***Салкын җилләр бераз тузгач,***
***Җиргә карлар явып узгач,***
***Ул тау шуарга киткән...***(анча)




**Газетаны оештыручы һәм баш редактор:** Гариф Ахунов исемендәге Казанбаш төп гомуми белем мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы: *Габдрахманова Л.М., китапханәче: Рәхимова Р.З.*

**Редколлегия әгъзалары:** *Рамазанова Ф.Р., Фазлиева Р.Р., Гатауллина Г.Ф.*

**Индекс-** 422020
**Тираж-** 10 данә

**Адрес:** ТР,Арча районы, Мәктәп урамы, 94
Арча муниципаль районы “Гариф Ахунов исемендәге Казанбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе”





# ЧИШМӘ БАШЫ

“ Туган телне сөючеләр” нең матбугат үзәге

Гыйнвар, 2025 ел

№ 1


***Бу сан сәхифәләре***


- ✓ *Туган ягым табигате*
- ✓ *Укучылар иҗаты*
- ✓ *Мәктәп сулышы*
- ✓ *Кышкы мизгел*
- ✓ *Ял сәгатьләрендә*


## Гыйнвар иртәсе

***Гади бер көн, бер яңа көн***
***Тылсымлы кояш балкый.***
***Төн карасын җиңеп чыккан***
***Илаһи нурлар уйный.***

***Гыйнвар иртәсендә карлар***
***Җем-җем килә бар җирдә,***
***Дуслашып яктылык белән***
***Күз карасына иңә.***

***Зәңгәр күкнең сәхнәсеннән***
***Энҗе бөртек коела,***
***Хикмәтле ки, битләремнән***
***Үпкән кебек тоела.***

*****

Ел башлана гыйнвардан,
Карасак календарьдан.
Гыйнвар бит ул кыш ае,
Карлар яусын көн саен!

Кар өеме - ул шатлык,
Ул бәрәкәт, ул муллык.
Бала-чага уйнасын,
Йөзләре алсулансын!

Алсу Галеева (Сафина)

## ТУГАН ЯК

Кояш нурлары җиргә төшкән,
Су буйларында чәчәкләр үскән.
Күкләр зәңгәр, болытлар ак,
Табигатьтә һәр нәрсә – ялкын, хак.

Урманнарда җил искәндә,
Кошлар сайрый, күңелгә шаулап.
Табигатьнең матурлыгын – безнең байлык,
Саклыйк аны, безнең туган як.

Чишмәләр аккан, суы саф,
Табигатьтә һәр мизгел – яңа хикмәт.
Кояш батканда, төн килә,
Табигатьнең серләре – безгә мәгълүм түгел.

Язгы яфраклар, көзге алтын,
Табигать - безнең гомер юлдашы.
Саклыйк аны, хөрмәтлик,
Табигать – безнең иң зур бәхет!

***Исмәгыйлева Сөембикә, 9 сыйныф укучысы***



*Кабартма*

***Пичтән чыккан тәмле исне,***
***Илләр исен тарата,***
***Мичтә таба эчләрендә***
***Күперел пешкән кабартма.***
***Үзе пешкән, йөзе килгән,***

***Кабартма бигрәк тәмле.***
***Самавары кайнап тора,***
***Өстәл өсте бик ямьле.***

***Сөтле чәй белән кабартма:***
***Телләреңне йотарлык...***
***Милли ризыккабартмабыз –***
***Татар өчен горурлык.***

***Сафина Сөмбел, 6 сыйныф укучысы***



***Кышкы көн***

***Бүген тышта нинди матур,***
***Шундый матур кар ява.***
***Һава салкын, битләр туңа,***
***Кар җиргә юрган яба.***

***Кар бабай ясарга диеп***
***Чыкты барча балалар,***
***Тауның иң биек ягына***
***Шатланышып чабалар.***

***Кар бабайны ясап куйгач***
***Чиләк, себерке алып,***
***Шундый матур булды диеп***
***Торалар хәйран калып.***

***Мөсәгыйтов Кәрим, 5 сыйныф укучысы***



Укучылар иҗаты

## ТЫНЫЧЛЫК ТАВЫ

Авылыбыздан ерак түгел коры елга бар.Үзәннәрендә кызарып җиләк пешә,язын аллы-гөлле чәчәкләргә күмелә.Бу урынны әнием “Тынычлык тавы” дип ата йөртә.Үземне белә башлаганнан бирле әнием белән әлеге урынга миндә еш киләм. Тау битләрендә зифа каеннар,мәңге яшел наратлар,бөдрә таллар, миләш, шомырт куаклары очрый. Тауның текә ярларына карлыгачлар оя кора.Дөрестән дә тыныч, рәхәт урын бу.Серле урын.Тауга килгәч мин әниемне сораулар белән аптыратып бетерәм. “Әнием бу коры елга ничек барлыкка килгән?”, “Нигә аның суы юк?”, “Тау битләренә агачларны кем утырткан?”, “ Нигә суы юк?”. Кайбер сорауларга хәтта әнием дә җавап бирә алмый. Бөтен сорауларга җавап табылып бетсә, кызыкта булмас иде. Менә шул серлелеге белән үзенә тарта да инде Тынычлык тавы.

Коры елганың астына ук төшеп,кар сулары юып чыгарган,ташлы сукмак буенча йөрергә яратам мин.Ә анда ташларның ниндиләре генә юк.Шома түгәрәкләре дә,челтәрләнеп беткәннәре дә,зәңгәрсу кызгылтлары да...Матур да, серле дә!Әлеге ташлы сукмак комлы, текә ярга илтә. Анысы тагын бер могҗиза.Шама гына түгел ул яр, киртләч – киртләч.Ә киртекләре шулкадәр төгәл, оста скульптор тырышкан диярсең.Әлеге шома өслеккә чокып мин дә сүрәт төшерәм... Әнием дару үләннәре, нарат күркәсе, җиләк җыя.Кабатланмас рәхәт мизгелләр бу.

Тынычлык тавы ел әйләнәсе безнең яраткан урыныбызга әйләнде. Бераз җылытып кисәк суытса кар өсте тыгызланып ката һәм аяк батмый башлый.Менә шул көннәрдә тау шуарга киләбез без коры елгага.Сөзәк урынны сайлап рәхәтләнеп шуабыз. Кочагын җәеп каршы ала тау, моңаеп озата.

Безнең гаҗәеп тауны сез дә килеп күрегез.Тынычлык тавы кунакларны ярата!

Шәрипов Азат, 4 сыйныф укучысы

# Мәктәп сулышы

### Җиңүләребез алда әле!

Спорт-сәламәтлекнең нигезе.Укучыларыбыз аның асылын яхшы аңлый.Тәнәфесләрдә спортзал ишекләре алар өчен ачык. Көрәш, баскетбол ,волейбол уеннарын ярата алар. Нәтиҗәсе дә куанычлы. Район күләмендә үткәрелгән көрәш ярышларында Хәйриев Нәфис 1 урын, Мөсәгыйтов Кәрим 2 урын, Хәйруллин Әмир мәктәбебезгә 3 урын алып кайттылар."Икенчене дә алып була иде,чүттән генә калды",-дип елмайды Әмир!Ә шулай да,әфарин,егетләр!

*Мәрданов Рафаэль Равилевич*
*физкультура укытучысы*





### Грант оттык.

*2024 нче елның октябрь-ноябрь айларында Министрлар Кабинетының карары нигезендә "Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыруда муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына ярдәм күрсәтү" грантын отуга бәйге уздырылды.*

*Республика бәйгесендә безнең мәктәп җиңү яулады, 500 мең сум күләмендә грант тапшырылды.*



# Кышкы мизгел

### Кыш килде

**Төренде дөнья акка –**
**Кыш килде туган якка.**
**Башланды суык көннәр,**
**Көннәрдән озын төннәр.**

**Кар өстендә күпме эз!**
**Күрмәсәгез, күрегез.**
**Куян азык эзләгән,**
**Төлке аны күзләгән.**

**Суык бабай кич – иртә**
**Борыннарны өшетә.**
**Ә кәндез кояш көлә:**
**-Түзегез, - ди, - яз килә!**

**Кыш килде, салкын урамда.**
**Ә без куркып тормыйбыз.**
**Чана-чаңгыларны алып,**
**Тауда шуып уйныйбыз.**

*Фазлиев Илзат,*
*6 сыйныф укучысы*

### Кышкы сынамышлар

*Кыш күп карлы булса, җәй яңгырлы булыр.
*Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.
*Утын сызгырса, көн суытыр.
*Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.
*Гыйнварның унында бәс төшсә, җәй яңгырлы килер.
*Моржадан чыккан төтен туры булып өскә менсә, көн аяза, суыта. Әгәр төтен җиргә ятса, көн җылыта.
*Яңа елда ябалак кар яуса, аннан соң һава җылы, юеш булыр.
*Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.

Кыш елның иң матур һәм тылсымлы вакыты. Урамнар ап-ак кар белән каплана,агачлар көмеш төскә керә,ә һавада бәйрәм рухы сизелә. Кышның иң көтеп алынган бәйрәмнәренең берсе - Яңа ел. Бу көнне һәркем могҗиза көтә,бүләкләр ала,гаиләсе белән җыела. Яңа ел төнендә матур итеп бизәлгән чыршы тирәсенә җыелабыз. Өйләребездә бәйрәм атмосферасы хөкем сөрә - төрле төстәге уенчыклар,гирляндалар,утлар балкый. Барлык якын кешеләр белән бергә җыелып,бер-берсен Яңа ел белән котлыйлар,бүләкләр бирәләр. Без, балалар, Кыш бабай белән Кар кызының килүен түземсезлек белән көтәбез.

Яңа ел бәйрәменнән соң кышкы каникуллар башлана. Бу вакытта мәктәптә укулар бетә, күңелле уеннар белән шөгыльләнә башлыйлар. Кардан төрле сыннар ясарга, дуслары белән чана, чаңгы шуарга йөриләр. Шулай ук китаплар укыйлар, кино карыйлар,гаиләләре белән сәяхәткә чыгалар. Кышкы каникул – ял итү, көч җыю һәм кышкы матурлыктан ләззәт алу өчен бик яхшы вакыт. Кышкы каникуллар бик тиз уза, әмма алар күңелле истәлекләр калдыра. Яңа ел һәм кышкы каникуллар балалар өчен елның иң яраткан вакытларының берсе. Алар бу вакытларны түземсезлек белән көтәләр һәм алардан һәрвакыт рәхәтлек алалар.

*Мөбәрәкшина Зәлия,*
*7 сыйныф укучысы*

